КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 май г.Казань № 377

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карары белән расланган 2024 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 декабрь, 1278 нче; 2022 ел, 25 июль, 716 нчы; 2022 ел, 30 ноябрь, 1270 нче; 2023 ел, 21 март, 305 нче; 2023 ел, 2 июнь, 680 нче; 2024 ел, 29 март, 202 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2024 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә, 5.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәп, үзгәреш кертергә:

«4) Россия Федерациясе Президентының «Хезмәткә сәләтсез гражданнарны тәрбияләүне гамәлгә ашыручы затларга компенсация түләүләре турында» 2006 елның 26 декабрендәге 1455 номерлы Указы нигезендә хезмәткә яраклы эшләмәүче зат өлкән яшьтәге гражданны (инвалидны) караган өчен ай саен компенсация түләве гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин